Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 11**

Шумково авылы 2019 елның 13 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының 2018 елның 30 ноябрендәге "Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында"Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында" 92- ЗРТ номерлы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 13 апрелендәге "Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эчендәге районнар территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик тәкъдимнәрне раслау турында" 711/пр номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Шумково авыл җирлеге" үзидарәлек берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карар проекты буенча ачык тыңлаулар йомгакларын карап, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә (Шумково авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 20 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) II бүлекне түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“каты коммуналь калдыклар – физик затлар тарафыннан куллану процессында торак урыннарында барлыкка килгән калдыклар, шулай ук шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында физик затлар тарафыннан торак урыннарында файдалану процессында үзләренең куллану сыйфатларын югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеге процессында барлыкка килгән составы буенча физик затлар тарафыннан куллану процессында торак урыннарында барлыкка килгән калдыкларга охшаш калдыклар керә;”.

“җитештерү һәм куллану калдыклары –җитештерү процессында, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки куллану процессында барлыкка килгән әлеге Федераль закон нигезендә бетерелә торган, бетерергә аталган яки бетерелергә тиешле матдәләр яки әйберләр;”.

“контейнер – эре габаритлы калдыклардан гайре каты коммуналь калдыкларны салу, урнаштыру өчен тәгаенләнгән чүп-чар туплагыч (җыйгыч);”.

“каты коммуналь калдыкларны чыгару – җыелу, туплану урыныннан эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, каты коммуналь калдыкларны күмү өчен файдаланылучы объектларга кадәр каты коммуналь калдыкларны күчерү, ташу;”.

“арборицидлар – чүп-чар булып торган агач-куак үсемлекләренә каршы кулланыла торган химик матдәләр;”.

“Сосновский балтырганы – эре үлән үсемлек, чатырлылар семьялыгының балтырган нәселе төре. Озак төзәлми торган яндыру, пешерү яралары китереп чыгарырга сәләтле үлән;”.

“гербицидлар – үсемлекләрне юк итү өчен кулланыла торган химик матдәләр;”.

1.2) II бүлекнең 42 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“орынып торучы янәшә территория – бинага, каралтыга, корылмага һәм җир кишәрлегенә, әгәр ул җир кишәрлеге үзидарәлек берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төре, функциональ билеләнеше, мәйданы һәм бүтән факторларга бәйле рәвештә барлыкка килгән очракта, килеп тоташкан гомуми файдаланудагы территория.

Орынып торучы янәшә территорияләрнең чикләрен раслау һәм үзгәртү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы тарафыннан орынып торучы янәшә территорияләрнең чикләре схемасын раслау юлы белән гамәлгә ашырыла”.

1.3) 4.6. пунктының 4.6.1.7 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

““4.6.1.7. Каты көнкүреш һәм эре габаритлы калдыкларны чыгаруны гамәлгә ашыра:

- күпфатирлы йортлардан – калдыклар белән эш итү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм I - IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыйнау, күчерү (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиягә ия юридик һәм физик затлар;

- индивидуаль торак өйләрдән – торак йортлар хуҗалары мөстәкыйль рәвештә үзләре яисә шартнамә буенча калдыклар белән эш итү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм I - IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыйнау, күчерү (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиягә ия юридик һәм физик затлар;

- гомуми файдаланудагы территорияләрдән һәм калдыклар вакытлыча тупланган урыннардан – калдыклар белән эш итү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм I - IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыйнау, күчерү (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиягә ия юридик һәм физик затлар;

- коммуналь калдыкларны һәм чүп-чарларны сәүдә һәм җәмәгать туклануы, мәдәният оешмаларыннан, балалар һәм дәвалау йортларыннан чыгару күрсәтелгән оешмалар, шулай ук калдыкларны булдыручылар тарафыннан шартнамәләр нигезендә I - IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыйнау, күчерү (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиягә ия махсуслашкан оешмалар;

-бүтән территорияләрдән – табигатьне саклау һәм санитария таләпләрен үтәү шарты белән әлеге территорияләргә хокукы булган индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар мөстәкыйль рәвештә яисә калдыклар белән эш итү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм I - IV класс хәтәрлектәге калдыкларны җыйнау, күчерү (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча лицензиягә ия юридик һәм физик затлар белән шартнамә буенча.

ККК (каты көнкүреш калдыкларын) һәм эрегабаритлы, төзелеш чүп-чарларын җыйнау һәм чыгару гамәлдәге норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә контейнерлы яки тарасыз система буенча гамәлгә ашырыла. ККК системалы рәвештә, туплануга карап, тыштагы һава температурасы +5 градус һәм аннан югары булганда – тәүлеккә бер мәртәбәдән, елның салкын вакытында (-5 градус һәм аннан түбән булганда) өч көнгә бер мәртәбәдән дә калмыйча чыгарыла. Шуның белән бергә чыгару ешлыгына бәйсез рәвештә контейнерларның тулып ашуы (чүпнең кырыйга коелуы) рөхсәт ителми. Контейнер мәйданчыкларындагы эре габаритлы һәм төзелеш чүпләрен чыгару тулуга карап, тик атнага бер тапкырдан да сирәк түгел.”.

1.4) IV бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.6.11 пункты белән тулыландырырга:

“4.6.11 Сосновский балтырганын бетерү буенча чаралар

Җир кишәрлекләренең хокукый ияләре милекләрендәге, ия булу яки файдаланудагы җир кишәрлекләрендәге Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар күрергә бурычлылар. Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелергә мөмкин:

химик юл белән – үсеп чыгу урыннарын гербицид һәм (яки) арборицидлар белән сиптерү;

механик юл белән – чабу, корыган үсемлекләрне җыю, тамыр системасын казып алу;

агротехник юл белән – туфракны эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.

Җир кишәрлекләреннән Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар үткәрмәү кисәтү яки административ штраф салуга сәбәп була.”.

2.Әлеге карар рәсми басылып чыгу (халыкка белдерелү) көненнән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Молодежная урамы, 5 йорт;Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы А.Р.Шәйдуллин